**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТҮКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423732, Түке авылы,
Илтимер урамы, 2 йорт.
тел. факс.: (85552) 3-44-61
e-mail: tuk-akt@yandex.ru

**СОВЕТ ТЮКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

423732, с. Тюково, ул. Илтимерова, дом 2. тел. факс.: (85552) 3-44-61 e-mail: tuk-akt@yandex.ru

КАРАР

2020 елнын 26 ноябре №11

Түке авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм куллану турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25,1,56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 13.11.2020ел Чәчер авылы 1 номерлы гражданнар җыены карары нигезендә,13.11.2020ел Зөбәер авылы 1 номерлы халык җыены карары нигезендә, 20.11.2020 Түке авылы 1 номерлыхалык җыены карары нигезендә, Түке авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ

1. 2021 елда Түке авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданга, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 1 Төркем инвалидларыннан тыш, 700 (җиде йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләүләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә.:

-Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру;

- Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;

- Җирлек чикләрендә автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

- Җирлек чикләрендә урамнарны яктыртуны оештыру.

2. Актаныш муниципаль районы Түке авыл җирлеге гражданнарының җыен нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Түке авыл җирлеге»бүлегендә урнаштырырга.

Җирлек башлыгы : Р.М.Нуртдинов